СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

20.04. 2022 ел № 77

“Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
"Тойгуҗа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә
муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче
гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар
тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы "Тойгуҗа авыл
җирлеге"муниципаль берәмлегендә
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан
керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру турында”
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге Советының карары
үз көчен югалткан дип тану хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә «Муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-13 номерлы аңлатмалары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 мартындагы 24 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга

2. "Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр,

чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге Советының 2023 елның 3 мартындагы 72 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга

3. Әлеге карарны Тойгуҗа авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларга, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырып игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе Р.А. Сафин